ШИМБӘ
27
ФЕВРАЛЬ
1943 ел.
№ 48 (6770)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ ҺӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ ҺӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ.

ЯЗГЫ ЧӘЧҮГӘ КАРАТА

М. И. КАЛИНИН

Советлар Союзының көньяк районнарында инде язгы чәчү башланды һәм ул атнадан-атнага төньякка таба тагын да арырак җәелә барачак. Һәркемгә билгеле, быел чәчү иң кыска срокларда һәм иң югары дәрәҗәдә үткәрелергә тиеш.

Безнең хәрби средстволарыбызның сыйфатын яхшырту өчен совет галимнәре һәм техниклары күп эшләделәр һәм шуның белән безнең дошманны җиңүебезне әзерләү эшендә зур роль уйнадылар. Галимнәр һәм агрономнар авыл хуҗалыгы өлкәсендә дә шундый ук эш үткәрергә тиешләр.

Хәзер газеталарда Тимирязев исемендәге авыл хуҗалыгы академиясенең Пенза өлкәсендәге колхозларны шефлыкка алганлыгы турында хәбәр күренде. Бу бик гүзәл башлангыч. Ләкин әгәр дә безнең авыл хуҗалыгы академиясенең тәэсире Советлар илендәге барлык колхозларга да җәелеп, барлык культураларга да кагылса, тагын да яхшырак булыр иде. Фән—бөек көч, гомумән аның йогынтысы гаять зур һәм авыл хуҗалыгы өлкәсендә ул гадәттән тыш нәтиҗәләр бирә ала.

Әлегә кадәр безнең колхозларның зур күпчелегендә авыл хуҗалыгы урыннардагы кешеләрнең тәҗрибәсе белән җәелеп килә иде. Күп кенә сәбәпләр аркасында хәзер безнең колхозлар тупланган бай тәҗрибәләре булган андый алдынгыларның шактый өлешен югалттылар. Шуңа күрә дә хәзер авыл хуҗалыгы фәненең барлык мәгълүматлары авыл хуҗалыгы эшләрендә, кайчан гына булганга караганда да күбрәк дәрәҗәдә, урыннардагы агрономнар аркылы практикада тормышка ашырылырга тиеш. Агроном районда күзәтеп торучы, инспекторлык итүче кеше булмыйча, завод цехындагы инженер кебек, авыл хуҗалыгы эшләренең турыдан-туры оештыручысы һәм җитәкчесе булырга тиеш.

Безнең авыл хуҗалыгы академиясе, аның галимнәре, профессорлары һәм барлык авыл хуҗалыгы фәне белгечләре алдында шушы сугышчан бурыч тора. Әгәр дә алар бу бурычны канәгатьләнерлек итеп үтәсәләр—үзләренең инженерлары, ягъни агрономнар һәм авыл хуҗалыгы механизаторлары аркылы үзләренең фәнни принципларын тормышка ашыра алсалар, шуның белән алар Советлар Ватаны һәм Кызыл Армиябез каршында үзләренең бурычларын үтәгән булырлар.

«Известия», 26 нчы февраль.

ХРОНИКА

Иптәш А. В. Хрулев хәрби эшкә күчү сәбәпле Юл Эшләре Халык Комиссары хезмәтләреннән азат ителде.

Юл Эшләре Халык Комиссары итеп иптәш Л. М. Каганович билгеләнде.

Дәүләт Оборона Комитеты Председателе Иосиф Виссарионович Сталинга

Данлыклы Кызыл Армиябезнең Сезнең акыллы җитәкчелегегездә уңышлы һөҗүм итүе белән рухланып, иптәш Сталин исемендәге 92 нче номерлы ике тапкыр орден белән бүләкләнгән заводның коллективы, Кызыл Армиянең 25 еллыгы көненә 10 полкны дивизия пушкалары белән һәм 3 танк бригадасын кораллар белән тәэмин итү буенча Сезгә биргән вәгъдәсен үтәде.

Бу кораллар завод хезмәт ияләренең үз акчаларына җитештерелде һәм Кызыл Армиягә тапшырылды.

«Сталинская артиллерия» не төзү өчен элек җыелган 4.132.000 сумга өстәмә рәвештә тагын 1.568.000 сум җыелды. Шулай итеп барлыгы 5.700.000 сум акча җыелды. Средство җыю дәвам итә.

Январь программасын завод 1942 нче елның декабрендә эшләп чыгарылганга караганда шактый артык итеп арттырып үтәде.

Кораллар чыгару буенча февраль планы заданиесе Кызыл Армия көненә үтәлде.

Завод коллективы фронтка кораллар белән ярдәм иткән хәлдә, хәрби хезмәткәрләрнең семьяларына һәм ватан сугышы инвалидларына һәртөрле ярдәмне күрсәтә. Материаль ярдәм күрсәтелми калган бер генә кызылармеец семьясы юк. Фронтовиклар семьяларына 200.000 сум күләмендә бер вакытлы пособие, 2.800 данә төрле кин куллану әйберләре һәм промышленность товарлары бирелде. Һәрбер семья ягулык белән тәэмин ителде. Бик күпләргә яхшы квартиралар бирелде. Ватанны саклаучыларның балалары балалар бакчаларына һәм ясләләргә урнаштырылды. Алар өчен балалар ашханәсе ачылды.

Завод коллективы корал җитештерүчеләрнең Бөтенсоюз социалистик ярышында инициатор булып тора, беренче көннәрдән башлап дәүләт планын һәм үзенең йөкләмәләрен арттырып үти. Завод коллективы биш ай буена ВКП(б) Үзәк Комитетының кызыл байрагын яулап алып зур мактаулыга ирешә һәм киләчәктә дә Дәүләт Оборона Комитетының теләсә нинди заданиесен үтәргә әзер тора.

Кадерле Иосиф Виссарионович, Сезнең йөзегездә туганыбыз героик Кызыл Армияне котлыйбыз һәм аңа киләчәктә дә дошманны җиңүне телибез.

Сезгә, кадерле Иосиф Виссарионович, чын йөрәктән сәламәтлек һәм ватаныбыз хезмәт ияләренең шатлыгы өчен озак еллар гомер телибез.

Кызыл Армиянең данлыклы 25 еллыгы көнендә без илебезнең барлык предприятиеләренә Беренче Май көненә Бөтенсоюз социалистик ярышын тагын да киң җәелдерергә чакырып мөрәҗәгать итәбез. Завод коллективы, бәйрәм алды социалистик ярышын башлап, үз өстенә түбәндәге йөкләмәләрне ала:

1. Март һәм апрель программасын срогыннан элек үтәргә һәм планнан тыш һәм эшләүчеләрнең саклык акчаларына төзеп 12 полк өчен дивизия пушкалары һәм 4 танк бригадасы өчен кораллар бирергә.

2. Немец оккупантларыннан зарар күргән районнарга ярдәм итү фондына заводның ярдәмче хуҗалыгыннан 25 баш терлек, 3 мең пот яшелчә һәм орлык бирергә һәм Сталинград шәһәренең кораллар җитештерү промышленностен аякка бастыруда кирәкле ярдәмне күрсәтергә.

Яшәсен безнең ватаныбызның сакчысы, Ленин—Сталин тарафыннан төзелгән героик Кызыл Армия!

Яшәсен социализм иленең кораллы көчләренең Верховный Баш Командующие, даһи стратег һәм бөек полководец иптәш Сталин!

Эшчеләр, инженерлар, техниклар һәм хезмәткәрләр тапшыруы буенча:

Завод директоры **ЕЛЯН.**
ВКП(б) Үзәк Комитеты парторгы **ПРОСКУРИН.**
Завод баш инженеры **ОЛЕВСКИЙ.**
Эшчеләрне тәэмин итү буенча директор урынбасары **САМСОНОВ.**
Завком председателе **БЕЛОПРОСОВ.**
ВЛКСМ Үзәк Комитеты комсоргы **ГУСЕВ.**
Цех начальниклары **ПЕРМИТИН, ФИЛЬШТЕЙН, АБРАМОВ.**
Завод стахановчылары **БУКАРЕВ, ЧЕРНОДУБОВ, ЗАХАРОВ, ЦАПЛИН.**

СТАЛИН ИСЕМЕНДӘГЕ 92 НЧЕ НОМЕРЛЫ ЗАВОД ДИРЕКТОРЫ ИПТӘШ **ЕЛЯНГА.** ВКП(б) ҮЗӘК КОМИТЕТЫ ПАРТОРГЫ ИПТӘШ **ПРОСКУРИНГА.** ЗАВОДНЫҢ БАШ ИНЖЕНЕРЫ ИПТӘШ **ОЛЕВСКИЙГА.** ЭШЧЕЛӘРНЕ ТӘЭМИН ИТҮ БУЕНЧА ДИРЕКТОР УРЫНБАСАРЫ ИПТӘШ **САМСОНОВКА.** ЗАВКОМ ПРЕДСЕДАТЕЛЕ ИПТӘШ **БЕЛОПРОСОВКА.** ВЛКСМ ҮЗӘК КОМИТЕТЫ КОМСОРГЫ ИПТӘШ **ГУСЕВКА.** ЦЕХ НАЧАЛЬНИКЛАРЫ **ПЕРМИТИН, ФИЛЬШТЕЙН, АБРАМОВ** ИПТӘШЛӘРГӘ. ЗАВОД СТАХАНОВЧЫЛАРЫ **БУКАРЕВ, ЧЕРНОДУБОВ, ЗАХАРОВ, ЦАПЛИН** ИПТӘШЛӘРГӘ

92 нче номерлы заводның элек җыйган 4.132.000 сумга өстәмә рәвештә тагын 1.568.000 сум акча җыеп бу средстволарга 12 полк өчен дивизия пушкалары һәм 3 танк бригадасы өчен кораллар төзегән, фронтовикларның семьяларына һәм ватан сугышы инвалидларына материаль ярдәм күрсәткән эшчеләренә, эшче хатын-кызларына, инженер-техник работникларына һәм хезмәткәрләренә минем туганнарча сәламымны һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

И. СТАЛИН.

Совет Информбюросыннан

26 нчы ФЕВРАЛЬГӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

26 нчы февральгә каршы төндә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак Н-че часть бик каты сугышта бер ротага якын немец пехотасын кырып ташлады. Икенче бер участокта безнең разведка отряды, төнлә белән дошман тылына барып чыгып, дошманның берничә ДЗОТ ын шартлатты һәм 40 ка якын гитлерчыны юк итте.

* * *

Ворошиловградтан көньяк-көнбатыштарак Н-че часть сугышчылары, кинәт удар ясап, немецлар тарафыннан көчле итеп ныгытылган, халык яши торган бер пунктны алдылар. Сугыш кырында дошманның 200 гә якын үле гәүдәләре калды. Берничә орудие, минометлар, шулай ук мина һәм граната склады кулга төшерелде.

* * *

Краматорскаядан көньяк-көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманның мотопехотасына һәм танкларына каршы каты сугышлар алып баруны дәвам иттерделәр. Н-че часть гитлерчыларның күп санлы контратакаларын кире кайтарды һәм бер батальоннан артык немец пехотасын юк итте. Дошманның 26 танкысы зарарланды һәм яндырылды. Икенче бер участокта немец автоматчикларының безнең частьлар тылына үтәргә маташкан бер группасы чолгап алынды һәм юк ителде.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүм операцияләре алып баруны дәвам иттерделәр. Безнең сугышчылар, халык яши торган бер пунктны алган чакта, 6 орудие 18 пулемет, танкка каршы ата торган 4 мылтык, бер ашлык склады һәм бер сугыш припаслары склады кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең хәрәкәттәге отрядыбыз дошманның бер колоннасын җимерде. 80 немец солдаты һәм офицеры юк ителде. Пленныйлар алынды.

* * *

Курскидан төньяктарак Н-че берләшмә частьлары һөҗүм сугышлары алып бардылар. Күп кенә участокларда немецлар контратакаларга күчкәннәр иде, ләкин алар дошман өчен зур югалтулар белән кире кайтарылдылар. Бер участокта гына да 200 гә якын гитлерчы кырып ташланды һәм немецларның 3 танкысы яндырылды. Икенче бер участокта совет танкистлары дошманны халык яши торган бер пункттан бәреп чыгардылар һәм танкка каршы ата торган 8 орудие, сугыш припаслары төялгән 5 автомашина кулга төшерделәр.

67 венгер солдаты үзләре теләп Кызыл Армия ягына чыктылар. Алар үзләре белән 5 пулемет һәм 59 винтовка алып килделәр.

* * *

Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Төнлә белән Н-че берләшмә частьлары, кискен атака нәтиҗәсендә, Ангелинская станциясен алдылар. Дошман гарнизоны юк ителде. Безнең сугышчылар, уңышны тагын да җәелдереп, Старониже-Стеблиевская район үзә-

(Ахыры 4 нче биттә).

МОСКВА, КРЕМЛЬ.

Иосиф Виссарионович Сталинга

Җиңүле Кызыл Армиябезнең юбилее көнендә руханилар һәм рус православие диненә ышанучылар исеменнән Сезне, бу армиянең баш командующие сыйфатында котлыйм, дошманны тулысынча җиңү шатлыгы кичерүегезне гыйбадәт кылып телим.

Дингә ышанучылар, Кызыл Армиягә ярдәм итәргә теләп, минем Димитрий Донской исемендә танклар колоннасы төзелешенә средстволар җыярга чакыруыма бик теләп кушылдылар.

Барлыгы 6 миллион сум чамасы акча һәм шуның өстенә бик күп алтын һәм көмеш әйберләр җыелды. Москва шәһәре һәм Москва өлкәсе руханилары һәм дингә ышанучылары 2 миллион сум җыеп, Куйбышев шәһәре руханилары һәм дингә ышанучылары 650.000 сум акча, алтын һәм көмеш әйберләр кертеп, Казан шәһәрендә акчалата 350 мең сум, бер кадак алтын һәм көмеш әйберләр җыеп, Саратов шәһәрендә 350.000 сум, Молотов шәһәрендә 300.000 сум, Пенза шәһәрендә 500.000 сум җыеп, шулай ук Ленинград епархиясе дә 500.000 сум җыеп аеруча зур тырышлык күрсәттеләр. Средстволар җыю дәвам итә.

Бу средстволарны Кызыл Армиянең юбилее көнендә рус православие дине руханиларыннан һәм дингә ышанучылардан бүләк итеп кабул итегез.

Патриарх урынын биләүче Сергий
Москва һәм Коломна митрополиты.

УЛЬЯНОВСК,

ПАТРИАРХ УРЫНЫН БИЛӘҮЧЕ, МОСКВА ҺӘМ КОЛОМНА МИТРОПОЛИТЫ СЕРГИЙГА

Димитрий Донской исемендә танклар колоннасы төзелешенә 6 миллион сум акча, алтын һәм көмеш әйберләр җыйган рус православие руханиларына һәм дингә ышанучыларына минем чын күңелдән сәламымны һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен тапшыруыгызны үтенәм.

И. СТАЛИН.

МОСКВА. ОБОРОНА ХАЛЫК КОМИССАРЫ, БАШ МИНИСТР СТАЛИНГА

Героик Кызыл Армиянең гомуми дошманны гүзәл җиңүләре барлык изелгән халыкларның һәм шул исәптән газап чигүче, ләкин буйсындырылмаган Югославия халкының да азатлыгы һәм яңадан тууы көнен якынайталар.

Кызыл Армия төзелүгә 25 ел тулу уңае белән мин Сезгә, аның Верховный Баш Командующиена, Югославиянең үз территориясендә дә, шулай ук аннан читтә дә булган коралы көчләре исеменнән һәм үз исемемнән чын күңелдән котлаулар җибәрәм һәм тирәнтеп соклануыбызны белдерәм.

ИОВАНОВИЧ.

Югославиянең баш министры.
Лондон, 22 февраль, 1943 ел.

ЮГОСЛАВИЯ БАШ МИНИСТРЫ ИОВАНОВИЧ ӘФӘНДЕГӘ

ЛОНДОН.

Кызыл Армиянең 25 еллыгы уңае белән һәм гомуми дошманыбызга каршы көрәштә совет гаскәрләренең уңышлары уңае белән Сезнең котлавыгыз өчен минем рәхмәтемне кабул итүегезне үтенәм.

И. СТАЛИН.

Москва, Кремль. 24 февраль, 1943 ел.

МОСКВА, КРЕМЛЬ

СССР ның коралы көчләре Верховный Баш Командующие И. В. СТАЛИН әфәндегә

Безнең гомуми дошманыбызга—немец фашизмына каршы героик Кызыл Армиянең хәрби уңышлары белән рухланган хәлдә, СССР дагы чех-словаклар хәрби частеның офицерлары һәм солдатлары, Совет—Германия фронтына барган чакта юлда, үз суммаларыннан «Либице» һәм «Лежаки» исемле танклар төзелешенә 100.000 сум акча җыйдылар һәм Дәүләт банкысына керттеләр.

Шул ук вакытта без Н. шәһәрендә яңа төзелә торган чех-словаклар частеның солдатларына һәм офицерларына мөрәҗәгать итеп, шул максат өчен үзләренең саклык акчаларын һәм безнең СССР хәрби заемының 100.000 сумлык облигацияләребезне кертергә чакырабыз.

Бу танкларны СССР дагы чех-словаклар хәрби часте составына кертү турында күрсәтмә бирүне үтенәбез. Чех-Словакия халкының тарихи явыз дошманнары булган немецларны кулыбызга корал тотып кыйнарга мөмкинлек биргән өчен Сезнең үзегезгә рәхмәт әйтәбез.

Без сугышка «Немец оккупантларына үлем» лозунгысы белән барабыз һәм Сезгә Кызыл Армия командованиесенең һәрбер приказын намус белән үтәячәгебезгә вәгъдә бирәбез.

СССР дагы чех-словаклар хәрби частеның командиры полковник Л. И. СВОБОДА.

СССР ХАЛЫК КОМИССАРЛАРЫ СОВЕТЫНДА

ҮЗЕНЕҢ ХЕЗМӘТЛӘРЕН БАШКАРГАН ЧАКТА ҺӘЛАК БУЛГАН, ИКЕ ТАПКЫР СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ, АВИАЦИЯ ГЕНЕРАЛ-ЛЕЙТЕНАНТЫ ГРИГОРИЙ ПАНТЕЛЕЕВИЧ КРАВЧЕНКО ИПТӘШНЕҢ АТА-АНАЛАРЫНА БЕР ТАПКЫР ПОСОБИЕ БИРҮ ҺӘМ ПЕРСОНАЛЬ ПЕНСИЯ БИЛГЕЛӘҮ ТУРЫНДА

ССР Союзы Халык Комиссарлары Советы карар бирде:

1. Ике тапкыр Советлар Союзы Герое, авиация генерал-лейтенанты Григорий Пантелеевич Кравченконың ата-аналарына —атасы Пантелей Никитович Кравченкога һәм анасы Мария Михайловна Кравченкога 25.000 сум пособие бирергә.

2. Атасы Пантелей Никитович Кравченкога һәм анасы Мария Михайловна Кравченкога, гомерлеккә, ай саен 6 әр йөз сум персональ пенсия билгеләргә.

3. Иптәш Кравченконы күмүне дәүләт исәбенә алырга.

Москва, Кремль. 25 февраль, 1943 ел.

Бер частьта, бер пулемет расчетында ике туган—Иосиф һәм Никита Следневлар хезмәт итәләр. Алар икесе дә Кызыл Йолдыз ордены белән бүләкләнделәр. Алар, дошманның бик күп контратакаларын кире кайтарып һәм һөҗүм итеп, үзләренең «Максим» нары белән йөздән артык фашистны кырдылар. Күптән түгел бу пулемет уты мастерлары пулеметчы кыз Елена Гайдова белән тәҗрибә уртаклашу үткәрделәр. Иптәш Гайдова сугышка кадәр Көнбатыш тимер юлының Гредякино станциясендә ремонт эшендә эшләгән. Сугыш башлангач үзе теләп армиягә киткән һәм хәзер дошманга каршы батырларча көрәш алып бара. Рәсемдә: Иосиф һәм Никита Следневлар пулеметчы кыз Елена Гайдова белән беседа үткәрәләр.

ТАСС фотохроникасы.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Партия кабинетларының эшләрен яңа таләпләр югарылыгына

Германия империалистларына каршы бөек ватан сугышы көннәрендә агитация-пропаганда работниклары һәм партия кабинетлары алдында халыкның киң катлавы арасында масса-политик эшне тагын да көчәйтү бурычы тора.

Безнең җитәкче кадрларыбызның политик яктан тотнаклы һәм теоретик яктан әзерлекле булулары, марксизм-ленинизм теориясе мәсьәләләрен һәм партиябезнең тарихын системалы рәвештә өйрәнүләре хәзер бигрәк тә әһәмиятле.

Татарстанда күп кенә партия кабинетлары үзләренең бурычларын бик дөрес аңладылар һәм эшне сугыш заманы шартларына яраклаштырып үзгәртеп кордылар. Алар, масса арасында агитация алып бару мәсьәләләренә тирәнтен игътибар биреп, шул ук вакытта җитәкче кадрларны һәм агитация-пропаганда кадрларын идея-политик яктан тәрбияләү эшен дә шактый җәелдерделәр.

Мәсәлән, ВКП(б) ның Алабуга райкомы парткабинеты (мөдире иптәш Черняева) партия-совет активы өчен системалы рәвештә лекцияләр үткәрә, колхозларда һәм предприятиеләрдә «Агымдагы момент турында», «Халыкара хәл турында», «Рус халкының героик тарихы» һәм башкалар турында лекцияләр оештыра. Бу лекцияләрнең халыкның төрле катлауларына карап оештырылуы һәм аның җирле материаллар белән бәйләп үткәрелүе аеруча уңышлы факт булып тора.

Лекцияләр укуга районның партия активы һәм фән көчләре тартылган. ВКП(б) райкомы секретарьлары Петров, Сидоров, пропаганда һәм агитация бүлеге мөдире Катков һәм башка иптәшләр еш кына лекцияләр укыйлар. Агымдагы момент турындагы лекцияләрне халык аеруча яратып тыңлый. Аларда уртача 500—800 кеше катнаша. Үткән елның икенче яртысында шундый лекцияләр район үзәгендә 28 тапкыр һәм колхозларда 392 тапкыр булган.

Бу парткабинет янында «Авыл хуҗалыгы», «Балаларны фашистлар варварлыгыннан яклау өчен», «Ватан сугышы геройлары», «Социалистик хезмәт геройлары» һәм башка темалардагы күргәзмәләр оештырылган.

Акташ район парткабинеты эшендә дә уңышлы тәҗрибәләр бар. Биредә теоретик беседалар үткәрү өчен агитаторларның куст семинарларыннан уңышлы рәвештә файдаланыла. Ул семинарларга алдан яхшы әзерлек алып барыла. Мәсәлән, иптәш Сталинның «Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 25 еллыгы турында» гы докладь буенча үткәрелгән беседаларга агитаторлар докладны яхшылап укып килгәннәр. Беседалар бик җанлы үткән.

Бөгелмә район парткабинеты да (мөдире иптәш Малухина) үзлегеннән политик белем алучы актив белән системалы рәвештә эш алып бара. 1942 нче елның икенче яртысында гына да 32 тапкыр групповой, 130 тапкыр индивидуаль консультацияләр үткәргән.

Парткабинет янында гомуми тарих түгәрәге эшли. Хәрби почмак, агитатор-пропагандист почмагы һәм күргәзмәләр оештырылган. Иптәш Сталинның «Бөек Октябрь Социалистик революциясенең 25 еллыгы турында» гы докладь, «Экономия режимы—сугыш заманының законы» дигән темадагы күргәзмәләр үзләренә игътибарны аеруча тарталар.

Тәтеш, Шириәмәт, Беренче Май һәм башка кайбер районнарның партия кабинетлары эшендә дә шактый уңышлар бар.

Шуның белән бергә, республикабызда үзләренең эшләрен хәзерге таләпләргә җавап бирерлек итеп оештырмаган парткабинетлар бар әле. Мәсәлән, Тәмте район парткабинетында 1942 нче елның 7 ае эчендә, марксизм-ленинизм теориясен өйрәнүчеләргә ярдәм итү буенча бер генә лекция дә үткәрелмәгән. Бу районда, гомумән, активның үзләренең белемнәрен күтәрү өстендә эшләүләре һич тә канәгатьләнерлек түгел.

Буинск районы парткабинетында совет учреждениеләре оештыра торган һәртөрле киңәшмәләр, утырышлар, җыелышлар гына үткәрелә. Парткабинет үзлекләреннән политик белем алучыларга булышлык итми, агитаторлар белән кирәкле эш алып бармый.

Питрәч, Әлмәт, Кама тамагы, Мамадыш, Югары Ослан, Кузнечиха районнарындагы парткабинетлар да бик йомшак эшлиләр.

Бу кимчелекләр, ВКП(б) райкомнарының парткабинетлар эшенә тиешенчә игътибар бирмәүләре һәм йомшак җитәкчелек итүләренең нәтиҗәсе булып тора. Бу җитешсезлекләр иң кыска вакыт эчендә бетерелергә, парткабинетларның эше ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ВКП(б) Өлкә Комитеты күрсәтмәләренә тулысынча туры китереп үзгәртеп корылырга тиеш.

Партия кабинетлары работниклары пропаганда һәм агитация буенча барлык чараларны үткәрүдә үзләренең оештыручылык рольләрен тиешле югарылыкка күтәрергә, агитаторларның һәм пропагандистларның яхшы эш тәҗрибәләрен җәелдерергә тиешләр. Җитәкче кадрларның үзлекләреннән политик белем алуларын оештыруга, партия кандидатларының, бигрәк тә, партия сафларына яңа алынган иптәшләрнең укуларын оештыруга аеруча игътибар бирергә кирәк. Партия-совет активының идея-теория дәрәҗәсен күтәрү буенча аларга булышлык итүнең барлык формаларыннан киң күләмдә файдаланырга кирәк.

Е. ЕВДОКИМОВА,

ВКП(б) Өлкә Комитетының телдән һәм матбугат аркылы пропаганда алып бару секторы мөдире.

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказы хезмәт фронтында яңа җиңүләргә рухландыра!

Яңа йөкләмәләр

ТЕЛӘЧЕ, 26 февраль. (Телефон буенча). Кичә, 25 нче февральдә, район үзәгендә ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленум карарларын өйрәнүгә багышланган җыелыш булды. Җыелыш алдыннан иптәш Сталинның приказын өйрәнү оештырылды. Җыелышта 125 кеше катнашты. Иптәш Сталин приказын өйрәнгәч, җыелышта катнашучылар язгы чәчүгә әзерлекне яхшы итеп тәгалләү, 1943 нче елда мул иген уңышы алуга ирешү, фронтка бирелә торган ярдәмне тагын да яхшырту буенча аерым йөкләмәләр алып, Кызыл йолдыз районын социалистик ярышка чакырдылар.

Җыелышта катнашучылар дәүләткә ашлык тапшыруны 10 нчы мартка тәмамларга, ит, сөт һәм башка продуктлар тапшыруны вакытында үтәргә йөкләмә алдылар.

Янсыңар авыл советы председателе иптәш Иванов, самолетлар эскадрильясы төзүгә 130 мең сум акча тупларга йөкләмә алып, башка авыл советы председательләрен ярышка чакырды. Самолетлар эскадрильясы төзүгә бу авыл советы буенча 120 мең сум акча тапшырылды инде.

З. ИВАНОВ.

* * *

АПАС, 26 февраль. (Телефон буенча). «Яңа ил» колхозы членнары митингысы булды. Митингта иптәш Сталинның приказы өйрәнелде. Бу колхоз язгы чәчүгә әзерлекне барлык тармаклар буенча да Кызыл Армиянең 25 еллыгына кадәр үк тулысы белән тәгалләгән иде. Митингта катнашучы колхозчылар чәчүгә әзерлекне тагын бер кат тикшереп чыгарга булдылар.

Митингта язгы чәчүгә әзерлекне яхшы итеп тәгалләү, чәчүне югары сыйфатлы итеп үткәрү буенча районның барлык колхозчыларына мөрәҗәгать кабул ителде. Алар шулай ук терлекчелек планын үтәү буенча да йөкләмәләр алдылар.

ТИМЕР ЮЛЧЫЛАР ҖАВАБЫ

Казан тимер юлчылары Кызыл Армиянең 25 еллыгын бәйрәм итү алдыннан гына бөек юлбашчыбыз һәм полководецыбыз иптәш Сталиннан котлау телеграммасы алдылар. Бу телеграммада иптәш Сталин, «Казан тимер юлчысы» исемле танклар колоннасы төзелешенә 2 миллион сум акча һәм 1 миллион сумлык дәүләт заемнары облигацияләре керткән Казан тимер юлчыларына туганлык сәламын һәм Кызыл Армиянең рәхмәтен җибәрә.

Соңгы вакытта танклар төзелешенә акча туплау тагын да арттылы һәм акчалата 4,5 миллион сумга, дәүләт заемнары облигацияләре белән 1,5 миллион сумга җитте.

Иптәш Сталинның телеграммасы Казан тимер юлы работникларын Кызыл Армиягә ярдәмне тагын да көчәйтергә рухландыра. Акча туплау уңышлы рәвештә дәвам итә.

Тимер юлчылар Кызыл Армиянең 25 еллыгын яңа хезмәт батырлыклары белән билгеләп үттеләр.

Юдино депосы машинисты иптәш Ильин бәйрәм көннәрендәге бер рейсын һөҗүм итеп баручы Кызыл Армиябезгә багышлады. Ильин Юдино бүлеге диспетчеры Анташев белән ярыш договоры төзеде. Канаштан Юдинога кадәр булган участокта поезд техник тизлек нормасын арттырып үтәп барды. Төрләмә ягулык склады работниклары Ильинның локомотивын ягулык белән үз вакытында бик тиз тәэмин иттеләр. Поезд Юдинога, расписаниедә күрсәтелгәнгә караганда, 2 сәгать элек килеп җитте.

Ильинның напарнигы машинист Зуев, локомотивны кабул итеп, аны яңадан Канашка алып китте. Ул үзенең алдына локомотивның тәүлегенә уртача йөреш нормасын арттырып үтәү бурычын куйган иде. Поездны Канашка бик тиз китереп җиткереп, бригада ял итүдән баш тартты һәм ашыгыч рәвештә Юдинога кире китте.

Кривоносча эшләү нәтиҗәсендә Ильин һәм Зуев иптәшләр локомотивның тәүлегенә уртача йөрешен 116 километрга арттырдылар, өстәмә рәвештә бер поезд алып бардылар.

Лунинчылар Вырин һәм Буевич иптәшләр техник тизлек нормасын 12 километрга арттырып үтәделәр.

Юлдан шатлыклы хәбәрләр килеп тора. Кызыл Армиянең 25 еллыгы хөрмәтенә Әгерҗе участогы вагончылары февраль программасын 20 көндә тәгалләделәр. Муром вагончылары да планны срогыннан элек арттырып үтәделәр.

Танылган уйлап табучы, Сергач депосы слесаре орденлы иптәш Ротанов, Кызыл Армиягә бүләк итеп, бер станок ясауны тәгалләде. Бу станок хезмәт җитештерүчәнлеген 200 процентка арттыра.

Кызыл Армиянең туганы—тимер юл транспорты кешеләре әнә шулай эшлиләр.

Н. ГУСЕВ.

Барлык көчне — фронтка ярдәмгә

Верховный Баш Командующий иптәш Сталинның приказына багышланган митинглар Н-че заводның барлык цехларында да таять зур күтәренкелек белән үттеләр. Цехком председателе иптәш Прошина булган цехның иптәш Киян сменасы, бөек юлбашчыбызның приказына җавап итеп, 23 нче февральдә кич белән стахановчы вахтага басты. Бу смена, вахтага басып эшләвенең беренче көнендә үк, элек 12 сәгатьтә башкарыла торган эшне 8 сәгать эчендә тәгалләп чыкты. Аппаратчы Миңлегалиев смена заданиесен 151 процентка, аппаратчы Хөснетдинов — 155 процентка, Әхатова, Захарова, Ефимова, Ситдикова һ. б. иптәшләр заданиеләрне 148-150 процентка үтәделәр.

Икенче көнне иртә белән бу цехның мастер Антонова сменасы да стахановчы вахтага басты һәм заданиене 125 процентка үтәде.

8 нче мартка кадәр дәвам итәчәк бу стахановчы вахталар әнә шулай һәркөнне бик яхшы нәтиҗәләр бирәләр.

Механика цехында профгруппоргы иптәш Белов булган бригада, иптәш Сталинның приказына җавап итеп, тагын да яхшырак эшләргә сүз бирде һәм дәүләт хәрби заемы облигацияләрен оборона фондына кертергә булды. Иптәш Белов 700 сумлык облигация, сварщик Кожевников — 750 сумлык, кровельщик иптәш Егоров 300 сумлык облигацияләрен оборона фондына тапшырдылар. Завод ОРС ының 1 нче номерлы ашханәсе работникларыннан Строителева, Фәттахов, Платонова һ. б. иптәшләр, барлыгы 14.620 сумлык заем облигацияләре җыеп, оборона фондына тапшырдылар.

Заводның транспорт бүлеге эшчеләре, җаваплы бер задание алгач, тәүлек ярым цехтан китмичә эшләделәр һәм бу ашыгыч заданиене срогыннан элек үтәп чыктылар.

Иптәш Сталинның тарихи приказы завод коллективында моңа кадәр күрелмәгән хезмәт энтузиазмы тудырды. Коллективның һәрбер члены, барлык көчне фронтка ярдәмгә лозунгысы астында эшләп, юлбашчыбызның приказына практик эш белән җавап бирә.

Дубов сменасы Ереминча эшли

Канаш станциясе буенча дежурный иптәш Дубов, Ереминның алдынгы методын кулланып, станциянең поездлар үткәрү сәләтен арттыру өчен ныклы көрәш алып бара. Соңгы дежурстволарның берсендә аның җитәкчелегендәге смена поездларның 95 процентын расписание буенча җибәрде. Транзит вагоннар простое нормага карганда ике тапкырга диярлек кимителде. Коллектив 7 поездны 7-8 минут эчендә җибәрде.

Барлык профессия тимер юлчыларның бердәм эшләүләре эшнең уңышын тәэмин итте. Депо дежурные Крючков, склад дежурные Яковлев, вагоннар караучы Куприяновлар иптәш Дубов белән ярышалар һәм бер-берсенә актив төстә ярдәм итәләр.

Бер вагонның подшипнигын алыштырырга кирәк иде. Бу эш 6 минут эчендә үтәлде. Поезд юлга үз вакытында чыкты.



Рәсемдә: Питрәч МТС ының иптәш А. Мөхәррәмов җитәкчелегендәге ремонт бригадасы моторлар подшипнигына ремонт ясый. С. Парфенов фотосы.

РАЙОН ҖИР БҮЛЕГЕ МӨДИРЛӘРЕ, МТС ДИРЕКТОРЛАРЫ ҺӘМ АГРОНОМНАРНЫҢ РЕСПУБЛИКА КҮЛӘМЕНДӘГЕ КИҢӘШМӘСЕ

23—25 нче февральдә район җир бүлеге мөдирләре, МТС директорлары һәм өлкән агрономнарның катнашы белән республика күләмендә киңәшмә булды. Киңәшмәдә 1942 нче елгы авыл хуҗалыгы эшләренең йомгаклары һәм 1943 нче елның эш планы тикшерелде. Бу мәсьәлә буенча Татарстан җир эшләре халык комиссары иптәш Хөсәенов доклад ясады.

Доклад буенча фикер алышуларда 23 кеше катнашты. Алар арасында Балыкбистәсе МТС директоры Жданов, Алексеевский район җир бүлеге мөдире Нырков, агроном Кустовский (Усадтагы механизация мәктәбе), Казанбаш МТС директоры Әхметов һәм башка иптәшләр бар. Киңәшмәдә ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Бәдретдинов, авыл хуҗалыгы бүлеге мөдире иптәш Перов, ТАССР Совнаркомы председателе урынбасары иптәш Шибдин чыгыш ясадылар.

Казанбаш МТС ы директоры иптәш Әхметов МТС ның эш тәҗрибәләре турында сөйләде. Трактор бригадаларының еллык эш планын 116 процентка үтәүләрен, 13,6 тонна ягулыкка экономия ясауларын һәм төгәл графикның булуын, тракторчыларның намус хезмәте аркасында МТС ның шушы уңышларга ирешүен әйтте.

Һәрбер МТС шулай эшли ала, әлбәттә. Ләкин Соколка МТС ы директоры иптәш Терехин үзенең чыгышында трактор эшләренең өзелүен юкка гына төрле сылтаулар астына яшерергә маташты. Ул үзләрендәге кимчелекләрнең төп сәбәпләре—МТС та хезмәтнең дөрес оештырылмавы, тәртипнең булмавы турында бер сүз дә әйтмәде.

Киңәшмәгә катнашучылар үзләренең чыгышларында Наркомземны нык кына тәнкыйтьләделәр. Алар Наркомзем җитәкчеләреннән эштә булган кимчелекләрне ачып, эшлекле чыгыш ясауны көткәннәр иде. Ләкин җир эшләре халык комиссары урынбасары иптәш Сливовскийның чыгышы аларны канәгатьләндермәде. Иптәш Сливовский район җир бүлекләренең начар эшләүләре турында күп сөйләде. Үткәрелергә тиешле чараларны санап чыкты. Ләкин ул терлекчелек идарәсенең чиктән тыш начар эшләве турында читләтеп үтте. Нарком урынбасары иптәш Үзбеков та кадрлар әзерләү буенча эшнең начар торуы турында бер сүз дә әйтмәде.

Киңәшмә, шушылардан чыгып, үзенең күрсәтмәләрен бирде. Җир Эшләре Халык Комиссариатына тиз көндә ВКП(б) Өлкә Комитетының IX нчы пленумы күрсәтмәләре нигезендә эшне үзгәртеп корырга, булган кимчелекләрне ашыгыч рәвештә бетерү чараларын күрергә тәкъдим итте.

Киңәшмәнең соңгы утырышында ВКП(б) Өлкә Комитеты секретаре иптәш Колыбанов чыгыш ясады. Ул киңәшмәгә катнашучылардан хәзерге вакытта иң мөһим бурыч—иген уңышын күтәрүгә игътибар бирүне таләп итте.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

26 нчы ФЕВРАЛЬДӘГЕ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

(Ахыры. Башы 1 нче биттә).

гена бәреп керделәр. Урам сугышлары төн буе дәвам итте. Иртә белән безнең частьлар Староնиже-Стеблиевскаяны немец басып алучылардан бөтенләй чистарттылар. Сугыш кырында дошманның йөзләрчә үле гәүдәләре калды. Күп трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Орел өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды дошманның тылларына уңышлы рейд үткәргән. Партизаннар 240 немец солдатын һәм офицерын кырганнар, берничә урында тимер юлны шартлатканнар һәм 6 километр озынлыкта телефон-телеграф элемтәсе чыбыкларын кисеп алганнар. Икенче бер отрядның партизаннары немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарганнар. Бер паровоз, солдатлар утырган ике вагон һәм автомашиналар төялгән 3 платформа җимерелгән, 50 гитлерчы үтерелгән һәм яраланган.

* * *

Могилев өлкәсенең Костюковичи районының күп авылларында немец-фашист кабахәтләр канлы суеш оештырганнар. Немецларның җәза отрядлары, авылдан авылга йөреп, аларны тәмам яндырганнар. Фашист палачлар бер кешене дә исән калдырмаганнар, бөтен халыкны суйганнар. Гитлерчы кеше ашаучылар совет гражданнарыннан барлыгы 450 кешене терелəй яндырганнар һәм атып үтергәннәр.

26 нчы ФЕВРАЛЬДӘГЕ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

26 нчы февральдә безнең гаскәрләр элекке юнәлешләрдә һөҗүм сугышлары алып бардылар.

* * *

25 нче февральдә безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында немецларның 10 танкысын, гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 100 гә якын автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 5 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер тимер юл составын җимерделәр.

* * *

Ростов-Доннан көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманга каршы ут сугышы алып бардылар. Бер участокта Н-че часть сугышчылары дошман урнашкан урынга барып кереп, аларны окоплардан һәм ДЗОТ-лардан бәреп чыгардылар. 100 дән артык дошман солдатлары һәм офицерлары юк ителде. Эре калибрлы 3 пулемет, 9 автомат һәм 86 винтовка кулга төшерелде.

* * *

Краматорскаядан көньяк - көнбатыштарак безнең гаскәрләр дошманның мотопехотасына һәм танкларына каршы каты сугышлар алып бардылар. Немецлар, үзләренең моннан элек югалткан позицияләрен ничек кенә итеп булса да кайтарып алырга тырышып, күп санлы контратакалар ясадылар. Бер участокта гитлерчылар гаять зур югалтулар белән бер урында безнең частьлар урнашкан җиргә үтә алдылар. Бик каты сугыш ике көн дәвам итте. Совет сугышчылары 1.000 ләп гитлерчыны кырдылар, дошманның 22 танкысын, 52 автомашинасын яндырдылар һәм зарарладылар һәм дошманны алып ыргыттылар.

Һава сугышларында совет очучылары немецларның 15 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Харьковтан көнбатыштарак безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда дошман зур югалтуларга дучар ителде. Бер участокта гына да безнең сугышчылар 300 гә якын гитлерчыны юк иттеләр һәм 8 орудие, 20 пулемет, күп винтовкалар, бер сугыш припаслары склады, бер азык склады, 19 трактор һәм башка трофейлар кулга төшерделәр. Обояньнан көнбатыштарак безнең частьлар дошманның чолганып алынган группасын бетерделәр. 400 немец солдаты һәм офицеры плен алынды.

* * *

Курскидан көнбатыштарак безнең частьлар һөҗүм операцияләре алып бардылар. Бер участокта дошманның ике батальонга якын пехотасы контратака ясады. Немецлар каршы удар белән туктатылдылар, ә соңыннан үзләре өчен зур югалтулар белән алып ташландылар. Безнең сугышчылар, чигенүче дошманны куып барып, алга киттеләр һәм халык яши торган 4 пунктны алдылар.

* * *

Кубаньда безнең гаскәрләр һөҗүмне дәвам иттерделәр. Халык яши торган бер пункт районында булган сугышларда совет подразделениеләре 17 орудие, 11 автомашина, бер мина склады һәм 100.000 патрон кулга төшерделәр.

* * *

Минск өлкәсенең бер районында хәрәкәт итүче партизаннар отряды бер тимер юл станциясенә һөҗүм иткән. Ике арада башланып киткән сугышта партизаннар 40 гитлерчыны юк иткәннәр. Совет патриотлары Германиягә озатыр өчен әзерләп куелган 18.000 пот ашлыкны юк иткәннәр. Минск партизаннарының икенче бер отряды немецларның 4 эшелонын юлдан чыгарган. 3 паровоз, ягулык тутырылган 7 цистерна, солдатлар утырган 3 вагон һәм сугыш техникасы төялгән 17 платформа җимерелгән.

* * *

Немецларның 227 нче пехота дивизиясенең 328 нче гренадер полкы составындагы, танкка каршы оборона алып баручы 14 нче ротадан плен алынган обер-ефрейтор Эрих Пфальцграф совет хәрби властьларына түбәндәге белдерү белән мөрәҗәгать итте: «Немецлар армиясендә хезмәт итә башлаганнан бирле мин Голландиядә, Бельгиядә, Франциядә һәм Россиядә булдым. Мин немец солдатларының гражданнар халкын талауларын һәм үтерүләрен күрдем. Немец офицерлары һәркайда да халыкка ерткыч төстә карадылар. Россиягә поход башлар алдыннан солдатларга, сез гражданнар халкыннан, нинчә яшьтә һәм ирме-хатынмы булуларына карамастан, беркемне дә кызганмаска тиешсез дип инструкция бирделәр. Офицерлар: «Сез никадәр рәхимсезрәк эш итсәгез, руслар сезнең алдыгызда шул кадәр тизрәк тезләнәчәкләр» диделәр. Басып керү белән үк инде коточкыч күренешләр күрергә мөмкин иде, Солдатлар тоташ авылларны яндырдылар. Паникага бирелеп йөгерүче кешеләр арасында хатын-кызлар һәм балалар да барлыкны игътибарга алмыйча, аларны пулеметлардан аттылар. Гражданнар халкын үтерү хәрәкәт районын «җыештыру» һәм «чистарту» дип аталды. Киев тирәсен «чистартырга» задание алган бер СС батальоны берничә ун мең кешене, шул исәптән күп кенә хатын-кызларны һәм балаларны атып үтерде. Хәтта бик күпләрне күргән эсэсчылар да түзә алмадылар һәм аларның кайберләре массовый үтерүләрне дәвам иттерерлек хәлдә булмадылар. Шуннан соң офицерлар, гаять күп сандагы кешеләрне кыруны тәмам итү өчен, бөтен халыкны миналар куелган чокырларга куып кертергә һәм аларны шартлатырга приказ бирделәр. Пропаганда роталары бу үле гәүдәләр өемнәрен рәсемгә төшереп алдылар, аларны пленкага төшерделәр һәм кинофильмнар эшләп чыгардылар. Шуннан соң Германиядәге һәм Европаның ул басып алган илләрендәге барлык кинотеатрларда бу картиналарны озак вакыт русларның ерткычлыклары итеп күрсәттеләр. Немец газеталарының барысында да үле гәүдәләр рәсемнәре басылып чыкты һәм бу үтерүләр совет гаскәрләренең ерткычлыклары итеп күрсәтелде. Ләкин без, солдатлар немецлар пропагандасының немец гаскәрләре тарафыннан Россия территориясендә эшләнгән кыргый җинаятьләрне һәм үтерүләрне русларныкы итеп күрсәтүе белән миллионнарча кешеләрне алдавын белдек».

ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ ПРИКАЗЫ ТУРЫНДА РУЗВЕЛЬТ

ВАШИНГТОН, 23 февраль. (ТАСС). Ак Йортта булган матбугат конференциясендә Рузвельт, үзенә бирелгән сорауга җавап биреп, Сталин приказын әле укымаганлыгын әйткән. Автомобиль промышленнигы Форд тарафыннан оештырыла торган радиотапшыруларда катнашучы комментатор Годвин Рузвельтка түбәндәгечә сорау биргән: — Сез миңа Сталинның, Кызыл Армия Совет чикләренә барып җиткәч, минемчә, Советлар Союзының сугышны туктатачагын аңлата торган белдерүләрен төшендереп бирә алмассызмы? Моңа каршы Рузвельт, Сталинның мондый белдерү ясаган булуы бик икеле, дип җавап биргән. Рузвельт Годвинга җаваплы документларны җиңелчә аңлатудан сак булырга тәкъдим иткән.

Икенче бер корреспондент Рузвельттан, Сталинның, Советлар Союзы сугышның бөтен авырлыгын бер ялгызы үз җилкәсендә күтәреп бара дигән белдерүен аңлатып бирүне үтенгән. Рузвельт бу приказның аерым урыннарын гына укыганлыгын, приказның бөтен текстын әле хәзергә кадәр укымаганлыгын һәм шундый киң документның аз гына өлешенә аңлатма бирү куркынычлы икәнлекне белдергән.

«Сатердей ивнинг пост» журналында Форрест Дэвисның бер мәкаләсе басылып чыккан булган. Бу мәкаләдә Рузвельтның, гүяки, 1942 нче елның январенда 1942 нче елны нинди булса да икенче фронт ачарга ачыктан-ачык сүз биргәнлеге һәм ахырында икенче фронтны Африкада ачарга карар биргәнлеге әйтелгән булган. Шул мәкалә турындагы сорауга җавап биреп, Рузвельт болай дигән: «Билгеле, икенче фронт үзе нәрсә ул дигән мәсьәләдә хисапсыз күп һәм нәтиҗәсез бәхәсләр алып барырга мөмкин. Ләкин Франция Төньяк Африкасында яңа фронт туган булу фактын инкарь итәргә ярамый».

Лордлар палатасында Бивербрукның чыгышы

ЛОНДОН, 23 февраль. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, элекке авиация промышленносте министры булган лорд Бивербрук бүген Европада ашыгыч рәвештә икенче фронт ачарга бик кирәклек турында лордлар палатасында белдерү белән чыккан. Ул болай дигән:

—Союзниклар беренче булып удар ясарга һәм хәзер үк, немецлар үзләренең көчләрен яңадан оештырганчыга кадәр үк, удар ясарга тиешләр.

Африка кампаниясенең бик күп яхшы яклары бар. Ул Европага һөҗүм итү өчен нигез төзи. Ләкин Англиянең дә күп өстенлекләре бар. Англиядән торып һөҗүм иткәндә безнең Германиянеке шикелле үк һәм аннан да яхшырак тәэмин ителү юлларыбыз һәм авиация өлкәсендә зур мөмкинлекләребез булачак.

Бивербрук русларның икенче һөҗүменә нигезләнгән оптимизмны гаепләп болай дигән:

— Бу һөҗүм без көткәннән артык булып чыкты, ләкин безнең аңа тиешеннән артык исәп тотарга хакыбыз юк. Безнең алда зур куркынычлар тора.

Күчәр державаларының пропагандистлары тагын да коммунизм белән куркытырга маташалар, ләкин безне Россия строе аз гына да кызыксындырмый. Ике ил арасында якын дуслык мөнәсәбәтләре урнаштырылырга тиеш. Мин коммунист түгел, ләкин әйтергә тиешмен, Россия коммунизмы тарихта тиңдәше булмаган уңышлы ике кышкы һөҗүмгә җитәкчелек итте.

Аннары Бивербрук русларның территория һәм материаллар ягыннан булган авыр югалтулары турында искә төшереп үткән. Бивербрук болай дигән:

—Немецлар русларның һөҗүменнән айныганчыга кадәр без удар ясарга тиешбез. Шулай ук без ударны тиз ясарга тиешбез.

Вакыт факторы төп нәрсә булганлыктан, без хәзер Европага төньяк-көнбатыштан һәм Урта диңгез ягыннан бәреп керергә тиешбез. Дьепп тәҗрибәсе ярамый. Аның каравы Крит атавы иң кирәкле атака формасының бик матур мисалы булып тора. Дөрес, анда немецлар 16.000 кеше югалттылар, ләкин англичаннарның югалган 16.000 кешеләре бары тик хәбәрсез юкка чыгучылардан гына тора. Төньяк-Көнбатыш Германиягә һөҗүм итү уңайлы юл ачар иде, Франциядәге су асты көймәләре базаларының эшен кыенлаштырыр иде һәм Африка белән булган коммуникацияләрне кыскартыр иде. Ләкин бөтен нәрсә вакытка бәйләнгән. Тиешле сәгатьне сайлап алуның халыкның язмышын хәл итүе мөмкин.

АНГЛИЯДӘ КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ 25 ЕЛЛЫГЫН БӘЙРӘМ ИТҮ ТАНТАНАСЫ

ЛОНДОН, 23 февраль. (ТАСС). Глазгода, Манчестерда, Оксфордта Кызыл Армиянең 25 еллыгына багышланган митинглар булды. Глазгода булган митингта Англия хөкүмәте члены, Ланкастер герцоглыгы канцлеры Дафф Купер речь белән чыкты. Ул, үзләренең туктаусыз алга баруларын дәвам иттерүче совет гаскәрләрен котлады. Дафф Купер болай диде: «Алар кайчандыр җиңелмәслек булып саналган Германия армиясен, куркынган хайваннарны куып барган кебек, куалар. Россиядә Кызыл Армияне төзегән кешеләргә, аны корал белән тәэмин итүче ирләргә һәм хатын-кызларга, аның тактикасын һәм стратегиясен эшләгән бөек акыллы кешеләргә тиешле бәяне бирергә кирәк. Руслар батырлар гына түгел, бәлки Европа һәм бөтен дөнья тарихында торган саен зуррак роль уйнарга тиеш булган, бик бөек, бик акыллы, бик хезмәт сөючән, ерактан күрүчән һәм чын-чыннан культуралы халыклар».

Манчестерда булган митингта колонияләр министры Стэнли чыгып сөйләде. Ул болай диде: «Руслар һөҗүмгә күчтеләр һәм бу һөҗүмдә үзләренең батырлыкларын һәм сугыш осталыкларын күрсәтәләр. Туниста дошман тар-мар ителгәннән соң Европа ярына һөҗүм итү өчен киң мөмкинлекләр ачылачак. Без барыбыз да Кызыл Армия белән Германиядә очрашачагыбызга өметләнәбез».

Оксфордтагы митингта информация министры Брэкен башта иптәш Сталинның Лондондагы митингка җибәргән хатын укып чыкты. Аннары Брэкен болай диде: «Баш министр Сталин Оксфорд халкының батыр Кызыл Армиягә яхшы карашта булуына шик тотмасын. Кызыл Армия, һичшиксез, берләшкән милләтләрне яклаучы. Россия сугышта күп корбаннар бирә. Без, рус халкының яхшылыгына һәм Кызыл Армиянең батырлыгына ихтирам белән карап, Россия биргән корбаннар турында беркайчан да онытмаска тиешбез. Моны искә алып, без Россиягә булган бурычыбызны кайтарырга тиешле икәнлегебезне ачыграк аңларбыз һәм без бу бурычны кайтарырга тырышабыз да. Мин сезне ышандыра алам, баш министрдан алып түбәнгә таба, без барыбыз да беренче мөмкинлек булу белән үк Европаның төрле пунктларында һуннарга нык удар ясарга хәзер торабыз».

Җаваплы редактор И. ҮЗБЕКОВ.

Театрларда һәм киноларда

Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры. 28 нче февральдә иртә белән—**«Печән өстендәге эт»**, кич—**«Хуҗа Насретдин»**.

Татар дәүләт опера һәм балет театры. 27 нче февральдә—**«Травиата»**.

Зур драма театры. Бүген, 27 нче февральдә—**«Нашествие»**.

Дәүләт циркы. Бүген зур цирк тамашасы һәм французча көрәш ярышлары. Кич 8 сәгатьтә башлана.

Яшь тамашачылар театры. Бүген, 27 нче февральдә—**«Мәзәкчеләр»**.

«Электро» — **«Җиңелмәслекләр»**.

«Унион» — **«Таҗикстан улы»**.

«Пионер» көндез һәм кич — **«Райком секретаре»**.

«Чатҗы» — **«Антоша Рыбкин»**.

Татарстан Мәгариф Халык Комиссарияты, Таттосиздат, Татарстан Совет Язучылары Союзы һәм Татарстан тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институты карт журналист, тәрҗемәче, педагог һәм русча-татарча сүзлекләр авторы **ФАТИХ ӘМИРХАН II** иптәшнең, озак авырудан соң, шушы елның 25 нче февралендә, үлүен тирән кайгы белән белдерәләр һәм мәрхүмнең семьясының кайгысын уртаклашалар.

ХРОНИКА

— Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы Кузьма Мартович Пелипенко иптәшне Татарстан АССР Коммуналь хуҗалык халык комиссары хезмәтләреннән азат итәргә карар бирде.

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор, редактор урынбасары— АТС 76—29, секретарь, промышленность - транспорт һәм авыл хуҗалыгы бүлеге— АТС 79—29. типография 36—60.

ПФ1062 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФ ИЯСЕ № Заказ 310